ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.03.2018 Казан ш. № 62

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тотышына һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләрне саклау комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору турындагы законнарны саклау буенча контрольне көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431нче Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге Указы басылуга бәйле

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынында үз-үзләрен тотышына һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләрне саклау комиссиясе турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 15 мартындагы 62нче боерыгы белән расланган Нигезләмәгә, аны түбәндәге эчтәлектәге 3.4.3. пункты белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләре түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасының 3.1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрләрдә аңлатылган мәгълүматны;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан гарызнамәләр (запрослар) нигезендә алынган мәгълүматны;

в) әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасының 3.1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр яисә хәбәрләрне якынча алдан карау йомгаклары буенча дәлилләнгән нәтиҗә, һәм шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктларына ярашлы рәвештә карарларның берәрсен яисә башка төрле карар кабул итү өчен киңәшләр.»

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов